| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ** |
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | **ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР** |

**«28» декабрь 2022г.** **с. Тюлячи** **№ 289**

Теләче муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары – Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибен һәм срокларын раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 16 сентябрендәге 1569 номерлы «Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнарына (дәүләт органнарына), территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары белән идарә итү органнарына, җирле үзидарә органнарына, җирле администрация органнарына бюджет керемнәренең баш администраторы вәкаләтләрен беркетүгә һәм Россия Федерациясе субъекты бюджеты, территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты, җирле бюджетның керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслауга гомуми таләпләрне раслау турында» карары белән расланган Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнарына (дәүләт органнарына), территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары белән идарә итү органнарына, җирле үзидарә органнарына, җирле администрация органнарына бюджет керемнәренең баш администраторы вәкаләтләрен беркетүгә һәм Россия Федерациясе субъекты бюджеты, Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты, җирле бюджетның керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслауга гомуми таләпләрнең 10 пункты нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Кушымта итеп бирелгән Теләче муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары – Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибен һәм срокларын расларга.

2. Әлеге карар 2022-2023 елларга һәм 2024-2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының Финанс-бюджет палатасы рәисе Р.Р. Яхинга йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Ф.С. Вәлеев

Кушымта

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«28» 12 2022 № 289
карары белән расланган

Теләче муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары – Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибе һәм сроклары

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 16 сентябрендәге 1569 номерлы «Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнарына (дәүләт органнарына), территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары белән идарә итү органнарына, җирле үзидарә органнарына, җирле администрация органнарына бюджет керемнәренең баш администраторы вәкаләтләрен беркетүгә һәм Россия Федерациясе субъекты бюджеты, территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты, җирле бюджетның керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслауга гомуми таләпләрне раслау турында» карары белән расланган Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнарына (дәүләт органнарына), территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары белән идарә итү органнарына, җирле үзидарә органнарына, җирле администрация органнарына бюджет керемнәренең баш администраторы вәкаләтләрен беркетүгә һәм Россия Федерациясе субъекты бюджеты, Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты, җирле бюджетның керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслауга гомуми таләпләрнең 10 пункты нигезендә эшләнгән һәм Теләче муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары – Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибе һәм сроклары механизмын билгели.

2. Баш администраторларның составы һәм (яисә) функцияләре үзгәрү, шулай ук Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы бюджеты керемнәре классификациясе кодларын билгеләү һәм бирү принципларын үзгәртү очракларында,Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы бюджеты керемнәре классификациясенең баш администраторларына беркетелгән кодлар исемлегенә, шулай ук составына үзгәрешләр Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының Финанс-бюджет Палатасы боерыгы нигезендә кертелә, «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары – Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнары исемлеген раслау турында» 2021 елның 16 ноябрендәге 303 номерлы Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертмичә.

3. Исемлеккә үзгәрешләр федераль һәм региональ законнарга бюджет керемнәре классификациясенең баш администраторларына беркетелгән кодлары составындагы үзгәреш өлешендә үзгәрешләр кертелүгә карап кертелә.

Эшләр белән идарә итүче И. Т. Һадиев